МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

08.07.2024 Казан ш. №138

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә раслау турында» 2018 елның 22 маендагы 232 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы указы нигезендә боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә раслау турында» 2018 елның 22 маендагы 232 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Икътисад

министрлыгының 07.10.2022 ел, № 359, 09.03.2023 ел, № 57, 25.08.2023 ел, № 180 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре) мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмый калу яисә җайга салу турында чикләмәләрне һәм тыюларны, таләпләрне үтәвен тәэмин итүдә, шулай ук коррупциягә каршы тору максатларында алар тарафыннан «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законда, башка федераль законнарда билгеләнгән бурычлар үтәлешен (алга таба – хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу) тәэмин итүдә;»;

15 пунктны түбәндәге эчтәлектәге «е» пунктчасы белән тулыландырырга:

«е) дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүгә һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга комачаулаучы, аңа бәйле булмаган шартлар барлыкка килүе турында хәбәр итүе.»;

16.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16.4. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының «б» пунктчасында бишенче һәм «е» пунктчасында күрсәтелгән белдерү Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге яисә әйдәп баручы белгече тарафыннан карала, ул хәбәрләмәне карау нәтиҗәләре буенча нигезләнгән бәяләмә әзерләүне гамәлгә ашыра.»;

16.5 пунктында «15 пунктның «д» пунктчасында» сүзләрен «15 пунктның «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзләре белән алмаштырырга;

16.6 пунктта:

«а» пунктчасында «15 пунктның «д» пунктчасында» сүзләрен «әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзләре белән алмаштырырга;

«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне яисә хәбәрләмәләрне беренчел карау нәтиҗәләре буенча дәлилле нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 23, 24.3, 25.1, 25.2 пунктлары нигезендә карарларның берсен яисә башка төрле карарны кабул итү өчен киңәшләр.»;

17.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17.2. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән белдерүләр, кагыйдә буларак, Комиссиянең чираттагы (планга кертелгән) утырышында карала.»;

18 пунктта «15 пунктның «б» пунктчасы белән» сүзләрен «15 пунктның «б» һәм «е» пунктчалары белән» сүзләренә алмаштырырга;

18.1 пунктның «а» пунктчасында «15 пунктның «б» пунктчасы белән» сүзләрен «15 пунктның «б» һәм «е» пунктчалары белән» сүзләренә алмаштырырга;

25 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының «а», «б», «г», «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау йомгаклары буенча, моңа нигезләр булган очракта, Комиссия әлеге Нигезләмәнең 22-24.3, 25.1-25.2 пунктларында каралганнан башкачарак карар кабул итә ала. Мондый карар кабул итүнең нигезләре һәм мотивлары Комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.»;

түбәндәге эчтәлекле 25.2 пунктын өстәргә:

«25.2. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының «е» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган шартларның барлыкка килүе һәм аларның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүгә һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга мөмкинлек бирмәве арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булуын танырга;

б) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган шартларның барлыкка килүе һәм аларның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүгә һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга мөмкинлек бирмәве арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булмавын танырга.».

**Татарстан Республикасы**
**Премьер-министры урынбасары –**
**министр** **М.Р.Шаһиәхмәтов**